# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Бүләк торак
пунктында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

18 март 2024 ел № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЭ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге башлыгының 07.03.2024 елгы 1 номерлы “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бүләк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 09.12.2023 елгы 1 номерлы, “2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Бүләк торак пунктында гражданнардан узара салым кертү турында” 09.12.2023 елгы 2 номерлы гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бүләк торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында” карары нигезендә 2024 елның 18 мартында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:

“ Түбәндәге редакциядә гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны бәян итеп, 09.12.2023 №1 “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бүләк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында”, 09.12.2023 №2 “2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Бүләк торак пунктында гражданнардан узара салым кертү турында” гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертүгә ризамы:

«Сез 2024 елда Сарлы авыл җирлеге Бүләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, һәм гаилә әгъзасы махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән гаиләләрдән тыш, 500 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 250 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Бүләк торак пунктында урамнарны яктырту җайланмасы (урамнарны яктырту лампаларын һәм запас частьләрне (фотореле, клипслар, чыбыклар һәм башка кирәкле комплект детальләрен) сатып алу, урам яктырту лампаларын алыштыру буенча электр хезмәтләре өчен түләү);

- Бүләк торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү автомобиле йөртүчесенең хезмәте өчен түләү, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);

- Бүләк торак пункт территориясен төзекләндерү (үләнне механикалаштырылган чаптыру буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- Бүләк торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (тракторчының карны механикалаштырылган җыештыру буенча хезмәт күрсәтүләре өчен түләү, чит оешмаларның юлларны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу хезмәтләре);

- Бүләк торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр урнаштыру, традицион рәвештә күмү урыннарын төзекләндерү (каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, традицион каберлекләр урынында каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу)

- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, транспортировкалау һәм халыкка су бирү системаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Бүләк авылы Мәдәният йортына су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын проектлау һәм төзү)».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 172 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 98.

Тавыш бирү нәтижәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә буленде:

«РИЗА» позициясе өчен - 98, «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирүче юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Бүләк торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыеныц нәтиҗәләре - гамәлдә (дөрес) дип таныргa.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип таныргa: “ Түбәндәге редакциядә гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны бәян итеп, 09.12.2023 №1 “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бүләк торак пунктында гражданнар жыены нәтиҗәләре турында”, 09.12.2023 №2 “2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл жирлеге Бүләк торак

пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында” гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертүгә ризамы:

«Сез 2024 елда Сарлы авыл җирлеге Бүләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, һәм гаилә әгъзасы махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән гаиләләрдән тыш, 500 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 250 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Бүләк торак пунктында урамнарны яктырту җайланмасы (урамнарны яктырту лампаларын һәм запас частьләрне (фотореле, клипслар, чыбыклар һәм башка кирәкле комплект детальләрен) сатып алу, урам яктырту лампаларын алыштыру буенча электр хезмәтләре өчен түләү);

- Бүләк торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү автомобиле йөртүчесенең хезмәте өчен түләү, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);

- Бүләк торак пункт территориясен төзекләндерү (үләнне механикалаштырылган чаптыру буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- Бүләк торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (тракторчының карны механикалаштырылган җыештыру буенча хезмәт күрсәтүләре өчен түләү, чит оешмаларның юлларны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу хезмәтләре);

- Бүләк торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр урнаштыру, традицион рәвештә күмү урыннарын төзекләндерү (каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, традицион каберлекләр урынында каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, Бүләк авылындагы зиратны коймалау өчен материаллар сатып алу)

- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, транспортировкалау һәм халыкка су бирү системаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Бүләк авылы Мәдәният йортына су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын проектлау һәм төзү)»».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 172 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 98.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә буленде:

«РИЗА» позициясе өчен - 98, «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирүче юк.».

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Сарлы авыл жирлегенең мәгълумат стендларында урнаштырырга, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatar.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълуматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль районыныц Сарлы жирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция Министрлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Сарлы авыл җирлеге башлыгы
Азнакай муниципаль районы И.М. Камалетдинов